| | |
|---|---|
| **ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ<br>КАДЫБАШСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ<br>АГРЫЗСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН** | **ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ӘГЕРҖЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>КАДЫБАШ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ<br>БАШКАРМА КОМИТЕТЫ** |

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

14.03.2019 Кадыбаш авылы № 2

Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Кадыбаш авыл җирлегендә җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияле исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләр бәясен раслау турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Җирләү һәм җирләү эше турында» 1996 елның 12 гыйнварындагы 8-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында күмү һәм җирләү эше турында» Федераль законны гамәлгә ашыру чаралары хакында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2007 елның 18 маендагы 196 номерлы карары, «Россия Федерациясе хөкүмәтенең “2019 елда түләүләр, пособие һәм компенсацияләрне индексацияләү коэффициентын раслау турында” 2019 елның 24 гыйнварындагы 32 номерлы карары нигезендә Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Кадыбаш авыл җирлеге башкарма комитеты,

КАРАР БИРӘ:

1. 2019 елның 1 февраленнән Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Кадыбаш авыл җирлегендә җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияләнгән исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләрнең бәясен 1 нче кушымта һәм 2 нче кушымта нигезендә билгеләргә һәм гамәлгә кертергә.
2. Әлеге карарны Әгерҗе муниципаль районының рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында урнаштырырга.
3. Әлеге карар 2019 елның 1 февраленнән үз көченә керә.
4. Карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемә алам.

Җитәкче И.Г. Рамазанов

Татарстан Республикасы
Әгерҗе муниципаль районы
Кадыбаш  авыл җирлеге
Башкарма комитетының
14.03.2019 № 2 карарына
1-нче кушымта

Әгерҗе муниципаль районының Кадыбаш  авыл җирлегендә
2019 елның 1 февраленнән җирләү буенча хезмәтләрнең
гарантияле исемлеге бәясе

| **Хезмәт күрсәтү исеме** | **Стоимость услуг *(в руб.)*** |
|---|---|
| 1. Җирләү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү | 0 |
| 2. Табут һәм җирләү өчен кирәкле башка предметларны бирү һәм китерү | 2546,47 |
| 3. Үлгән кешенең мәетен (җәсәдләрен) зиратка алып бару | 625 |
| 4. Җирләү (кабер казу һәм күмү) | 2775 |
| **Барлыгы** | **5946,47** |

Татарстан Республикасы
Әгерҗе муниципаль районы
Кадыбаш  авыл җирлеге
Башкарма комитетының
14.03.2019 № 2 карарына
2-нче кушымта

Әгерҗе муниципаль районының Кадыбаш  авыл җирлегендә
2019 елның 1 февраленнән якын һәм башка туганнары яисә законлы вәкиле
булмаган мәрхүмне җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияле исемлеге бәясе

| **Хезмәт күрсәтү исеме** | **Стоимость услуг** ***(в руб.)*** |
|---|---|
| 1. Җирләү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү | 0 |
| 2. Мәрхүмгә гыйбадәт киеме кигезү | 458 |
| 3. Табут һәм җирләү өчен кирәкле башка предметларны бирү һәм китерү | 2295 |
| 4. Үлгән кешенең мәетен (җәсәдләрен) зиратка алып бару | 563 |
| 5. Җирләү (кабер казу һәм күмү) | 2630,47 |
| **Барлыгы** | **5946,47** |